| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2022 елның гыйнвары-декабре |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларыда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру<br>2. Балаларның һәм яшьләрнең көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында сменаларны оештыру.<br>3. Палатка тибындагы лагерьда профильле сменаларда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру<br>4. Авыр тормыш хәлендә булган балалар һәм яшьләр өчен лагерьда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2022 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 4321,1 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары – 4277,90 мең сум;<br>җирле бюджет акчалары – 43,2 мең сум |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларның гомуми саныннан 60 процenttан да ким булмаган өлешен каникул вакытында төрле ял формалары белән тәэмин итү.<br>Ял сыйфатын һәм сәламәтләндерү дәрәҗәсен күтәрү, барлык программа чаралары киселешендә ачык чагылыш тапкан 80 процenttан да ким булмаган сәламәтләндерү нәтиҗәлелегенә (эффектына) ирешү. Лагерь тормышында катнашу процессында балаларның һәм яшьләрнең үз билгеләнешен табуы (самореализация), үсеше һәм камилләшүе |

## 1. Кереш

Җәйге ял - ул иң яхшы һәм кызыклы чор, чөнки балалар үз тормышларын кызыклы танышуларга, файдалы файдалы мавыгуларга һәм шөгыльләргә тулы итә ала, җырларга, биергә, уйнарга өйрәнә ала, буш вакытларын файдалы итеп үткәрергә, ягъни иҗади сәләтләрен үстерә ала. Балалар өчен сәламәтләндерү лагерьлары нәкъ менә шундый мөмкинлекләрне бирә дә инде. Җәйге ялны оештыру - белем бирү эшчәнлегенең мөһим аспектларының берсе, анда рухи-әхлакый, рациональ-танып-белү башлангычлары, экологик һәм патриотик тәрбия ярашып берләшергә тиеш. Каникуллар - бала тормышында мөһим чор. Педагоглар өчен бу вакыт аерым җаваплылык белән бәйле. Аларга катлаулы мәсьәләне хәл итәргә кирәк: балалар яхшы ял итсен, сәламәтлекләрен ныгытсын, көч-куәт тупласын, белемнәрен тулыландырсын, яңа әйберләргә өйрәнсен, яңа дуслар тапсын һәм шул ук вакытта өлкәннәрнең сак контроле астында булсыннар өчен ничек итеп, нинди формалар һәм методлар ярдәмендә каникул вакытын оештырырга.

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге формаларда башкарыла:

- балаларның һәм яшьләрнең көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларында балаларның һәм яшьләрнең ялы;

- балаларның һәм яшьләрнең хезмәт һәм ял лагерьларында ялы;

- балаларның һәм яшьләрнең палатка тибындагы лагерьда ялы;

- авыр тормыш хәлендә булган балалар һәм яшьләр өчен лагерьда балаларның һәм яшьләрнең ялы.

## 5. Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре

- 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларның гомуми саныннан 60 проценттан да ким булмаган өлешен каникул вакытында төрле ял формалары белән тәэмин итү.

- ял сыйфатын һәм сәламәтләндерү дәрәҗәсен күтәрү, барлык программа чаралары киселешендә ачык чагылыш тапкан 80 проценттан да ким булмаган сәламәтләндерү нәтиҗәлелегенә (эффектына) ирешү;

- балаларның һәм яшьләрнең сәламәтлеген ныгыту;

- балаларда һәм яшьләрдә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә кызыксыну уяту;

- төрле яштәге балалар арасында дуслыкны һәм хезмәттәшлекне ныгыту;

- балаларда һәм яшьләрдә әхлакый тәрбия дәрәҗәсен күтәрү;

- шәхси иминлек һәм тирә-юньдәгеләрнең иминлеге өчен җаваплылык хисе тәрбияләү;

- лагерь тормышында катнашу процессында балаларның һәм яшьләрнең үз билгеләнешен табуы (самореализация), үсеше һәм камилләшүе.

Әлеге программа кысаларында хезмәт күрсәтү күләмнәренең расланган нормативлары нигезендә үткәрелә торган чаралар

| № | Чаралар исеме | Үткәрү вакытлары | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру турында» карарны эшләү һәм раслау | Ноябрь, 2021 | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 2 | Сәламәтләндерү кампаниясен оештыручылар өчен республика семинарында катнашу | Февраль-март, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 3 | Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен гамәлгә ашыручы учреждениеләрне Татарстан Республикасы лагерьлары реестрына кертү | Апрель, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 4 | Сәламәтләндерү кампаниясенә әзерләнү | Ел дәвамында | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 5 | Җәйге һәм көзге чорда сәламәтләндерү кампаниясен оештыру буенча кирәкле документлар әзерләү | Ел дәвамында | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 6 | Балаларның ял һәм сәламәтләндерү оешмалары хезмәткәрләре өчен медицина тикшерүләре | Май, 2022 | «Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ, Балтач районының «Район үзәк хастаханәсе» ДАССУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | уздыру | | |
| 7 | Барлык төрдәге лагерьлар өчен санитар-эпидемиологик нәтиҗәләр алу өчен документлар әзерләү | Май, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 8 | Җәйге сәламәтләндерү кампаниясен уздыру турында документларны һәм мәгълүматны муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыру | Май, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 9 | Массакүләм мәгълүмат чараларында җәйге сәламәтләндерү кампаниясен үткәрүнең барышы турында мәгълүмат урнаштыру | Июнь-август,2022 | «Тамедиа» ААҖ филиалы «Хезмәт» редакциясе, «Кайтаваз» ТРК МКУ |
| 10 | Лагерьларны кабул итү актларын әзерләү | Май, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 11 | Гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларының көндезге ял (мәктәп яны) лагерьларда ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру | Июнь, ноябрь,2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 12 | Хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыру | Июнь, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| | Палаткалы лагерьда профильле сменалар оештыр | Июнь-август, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ |
| 13 | Авыр тормыш хәлендә булган | Июнь-август, 2022 | «Мәгариф идарәсе» МКУ, яшьләр эшләре һәм спорт |

